Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге
Яңа Дума авылында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2019 елның 29 ноябре № 5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Яңа Кармәт авыл җирлеге Яңа Дума авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2020 елда Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Яңа Дума авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, гражданнар өчен 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Яңа Дума авылының Калинин урамында каты өслекле юлны ремонтлау өчен товарлар сатып алу, эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү;;

- кышкы чорда Яңа Дума авылы эчендәге юлларны карап тоту

3. Әлеге карарны Яңа Кармәт авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнашкан рәсми сайтында: http://aksubaevo.tatar.ru Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында:http://pravo.tatarstan.ru игълан итәргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Кармәт авыл җирлеге башлыгы И. Р. Шакиров